ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «___» февраленнән № ____

2026 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы буенча күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү буенча иң чик индекс турында

2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын раслау тәртибен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында»гы боерыгының 4.1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның «__» февраленнән
___ номерлы карары белән
расланган

2026 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы

| № т/б | Муниципаль берәмлек | Чик индекс (процентлар) |
|---|---|---|
| | | 2026 елның 01 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр |
| 1 | Яңа Чишмә муниципаль районы | 20 |